ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старые Уруссу, ул. Советская,
д.16в, 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.: (85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 1 14 март 2024 ел

2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Уставының 22 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 25 мартында 17 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Иске Урыссу торак пункты, Совет урамы, 45А санлы йорт адресы буенча урнашкан Иске Урыссу авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында 2023 елның 21 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 21 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез эшләнәсе эшләрне түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 21 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 21 нгоябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара

салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертүгә сез ризамы:

«1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Иске Урыссу торак пунктының Инеш, 1 Май урамнары буенча юлларын норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Хәтер скверы территориясен хезмәтләндерү (килешү буенча эш өчен түләү);

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (торак пункт юллары эчендә тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

4) традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, ремонт, койма тоту, (зиратта хуҗалык инвентаре өчен бина төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

5) торак пункт территориясен төзекләндерү (милли Сабантуй бәйрәмен үткәрү урынын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Урыссу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://yutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http//pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар аның игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова